Хәмидуллина, Р. Акъегетнең ак күңелле өлкәннәре / Р. Хәмидуллина // Мәйдан. – 2025. – №6 (283). – Б. 108-119.

# «АКЪЕГЕТНЕҢ АК КҮҢЕЛЛЕ ӨЛКӘННӘРЕ»



Мин – һөнәрем буенча китапханәче. Кемнәр генә килми безнең китапханәгә? Якташларым да бик еш булалар – Мулла Иле, Норлат, Мамадыш, Ачасыр, Бузай, Акъегет һ.б. авылларда туып үсеп, бүгенге көндә Чаллы шәһәрендә яшәүче егет-кызлар. Очрашкач, исәнлек-саулык, туган-тумача турында сөйләшеп алырга да вакыт табабыз. Бер килүендә Акъегет кияве, безгә әби кунакка килде, дип әйтеп куйды. Минем, якташым янына кунакка барасым, әби белән күрешеп сөйләшәсем килеп китте. Саубуллашканда, кунакка киләм әле әби янына, дип әйтеп ташлаганымны оныткан да идем инде. Әби, теге кыз килмәде, дип хәбәр салгач, бармыйммы соң инде? Бардым.

Язның әле яңгыр, әле кар сибәләп торган моңсу бер мизгелендә әби яшәгән фатирның ишеген шакыдым. Мине кечкенә генә буйлы, күзләре генә түгел, йөзенең барлык күзәнәкләре елмаеп торган бер апа каршы алды. Вафирә апа белән күптәнге танышлар кебек сөйләшеп киткәнемне сизми дә калдым.

Адәм баласы үзе кичергән кайгы-хәсрәттән һәрвакыт нәтиҗә ясый, шул үткән мизгелләрне оныта алмый газаплана. Язмышы никадәр гыйбрәтле, ачы булмасын, аны күңел түрендә йөртә. Вафирә апаның да күңелендә йөргән хатирә-истәлекләре тыңлаучы барында чишелде дә китте. Ул сөйләде дә сөйләде, ә мин ул сөйләгәннәрне ак кәгазь битләренә төшереп калырга тырышып, яздым да яздым... Бигрәкләр дә гыйбрәтле язмыш хуҗасы булды минем әңгәмәдәшем Вафирә Сәлахетдин кызы Вәлитова...

## ФИНЛЯНДИЯ ҖИРЕ

Вафирә апа яшәгән Яшел Үзән районы Акъегет авылына да 1939 елгы ачлык кагылмый калмый.

– Бүгенгедәй хәтеремдә, алтынчы сыйныфта укып йөрим, – дип сүз башлады ул. – Әти, шушы ачлыктан гаиләсен саклап калырга теләп, «вербоваться» ителеп, Финляндиягә китәргә булды. Безнең авылдан – 7, күрше Норлат, Ачасырдан тагын гаиләләр бар. Гаиләбез ишле иде – әти-әнидән башка алты бала. Иң олы апага 18 яшь, ул, авылыбыз егетенә кияүгә чыгып, бармый калды. Миңа ундүрт яшь, калган энем-сеңелләрем берсеннән-берсе кечкенәләр. Атларга төялеп, Төрләмәгә кадәр килдек. Аннан, товар поездларына утырып, 15-20 көн бардык микән, анысы күңелемдә сакланмаган. Авылдан алып киткән җиңелчә генә азык-төлек белән барып җиттек кебек. Финляндиягә уңышлы гына барып урнаштык. Бигрәкләр дә матур җирләр иде. Тегендә бер йорт, мондарак тагын берәү. Барысы да агачлар белән әйләндереп алынган. Урман эчендә дә матур-матур йортлар утыралар. Без, җиде гаилә, кара-каршы йортлар салып, бер урам булып яши башладык. Йортыбыз зур, йокы, ашау бүлмәсе белән бергә дүрт бүлмәле иде. Әти-әниләр эшкә чыктылар. Алар, иген игеп, яшелчәлектә эшләделәр. Әй, урманнары матур, бай иде дә соң! Без, балалар, урманнан

кайтып кермәдек – җиләк, гөмбә җыйдык. Гөмбәне фин гаиләләренә бирәбез, алар, тозлап, хөкүмәткә тапшыралар иде. Әти белән бертуган абый, тәмле итеп тозлап, безгә дә гөмбә авыз иттерде.

Рәхәтнең дә михнәте була икән, бәхет тә ике яклы – шуны оныткан быз. Ике туганыма бу якның һавасы килешмәде. Еш кына авырый башладылар. Озак та тормый, ике һәм биш яшьлек туганнарым үлеп киттеләр. Бу кайгыларны уйламаганда, бик матур, рәхәт, тук яшәп калдык ул елларда. Калдык кына шул... Рәхәт булган җирне хәтәр сагалап йөри. 1941 елның 22 июнендә безгә сугыш дигән афәт килеп җитте. Башта сохарилар киптерергә куштылар. Яраклы кешеләрне сугышка озата башладылар. Әтиебезгә 55 яшь тулган, сугышка алыну яшеннән үткән иде. Беркөнне без, балалар, мунча кереп ятканда, әни килеп, тизрәк чыгыгыз, китәбез, диде. Тиз-тиз җыенгалап китеп тә бардык...

## БӘРӘҢГЕ КАБЫГЫН ДА ТАШЛАМАС ИДЕМ

Станциягә килдек, аннан поездларга төяп җибәрделәр. Перо дигән станциягә урнаштык, анда да озак торырга мөмкинчелек булмады. Тагын ераграк алып киттеләр. Ә сугыш дигәне безнең арттан калмый куды. Без Ленинград янындагы станциядә өч көн яттык. Менә анда инде сугыш куып җитте. Һавадан снарядлар ява, бер вагон онны бушатып бетергәннәр генә иде, снарядлар яңгыры астында калып, җир белән тигезләп тә куйды. Алда, артта, янда дошман ядрәсеннән үлгәннәрне әйтеп бетерерлек түгел. «Әти, нигә безгә ядрә тими?» – дим мин әтиемә. «Әй кызым, Ходай саклый безне, матур, зур эшләр өчен», – дия иде әти. Нинди матур эшләр? Безне, эшелоннарга төяп, тагын алып киттеләр. 1942 елның көзендә Ленинградка китереп бушаттылар. Дөресе дә шулай, бушаттылар, ачлыктан хәлсезләнгән идек, ашарга бер нәрсә юк. 125 грамм ипи бирәләр, анысын да пычакны суга манып кисәләр иде. Ике айга бер тапкыр 400 грамм ярма бирәләр иде кебек, анысы эләксә – эләгә, эләкмәсә – юк. Ул продукция карточкаларын югалтучылар да күп булды. Үзем дә бервакыт алып кайтканда икмәкне урлаттым, бер урыс егете алып качты. Ул елларда ачлыктан шешенеп үлүчеләр күп булды. Ул фаҗигагә юлыккан кешеләрнең халәтен сөйләп аңлатып кына булырлык түгел...

Әти исән чагында бирешмәдек, урманда күмелгән үле атларны казып чыгара идек. Әти балта белән шул ат итен турап, капчыкларга тутыра, без авылдашыбыз Гыйният абый кызы белән әнигә алып кайтабыз. Әни, берничә тапкыр кайнатып, итнең суын түгә. Әле шулай да иткә сибелгән дару исләре кала иде. Андый ат итләрен бик күпләп ашарга туры килде. Итен ашадык, ә атның тиресен яхшылап кырып, чистартып, юып, чәйнәп йөри идек. Ашыйсы килүне бераз гына оныттырып тора иде.

Әти исән калу, балаларын ач итмәүнең төрле юлларын эзләргә тырышты. Станциягә барып, бушатканда коелган он, горчица җыеп алып кайта иде. Менә шулардан әни чумар пешереп ашата иде. Сирәк кенә бәрәңге дә эләгә иде. Ул бәрәңгенең тәме хәзер дә тел очымда саклана кебек. Кабыгын да ашый идек без аның. Хыялларга бирелеп китеп: «Авылыма кайтсам, бәрәңгенең кабыгын бер дә ташламас идем», – дия идем. Без, балалар, дип, әтиебез үзе ач та калгандыр инде. Көннәрдән бер көнне аны да ачлык җиңде, кичтән йокларга яткан әтиебез иртә белән тормады. Бик яхшы хәтерлим, 1942 елның 14 гыйнвары иде бу. Без аның үле гәүдәсен күрше бүлмәгә чыгарып куйдык. Анда 7-8 мәет ята иде инде. Без тезелешеп яткан шул мәетләрне атлап йөрибез, шул бүлмәдә чәй кайнатабыз. Күпмедер вакыттан аларны алып киттеләр. Шәһәрдә үлем шулкадәр күп, җыеп йөрүчеләр мәетләрне алып китеп, күмеп өлгермиләр иде. Урамда да кеше мәетләрен бик еш күрергә туры килә

башлады. «Үлгән әтиләрен пешереп ашаган гаиләне төрмәгә алып киткәннәр» дигән сүзләрне дә ишеттек. Сугыш безне вакытыннан алда олыгайтты, курыкмаска өйрәтте, яңадан-яңа кайгы-хәсрәтләр биреп чыныктырды...

## БЕР ТУЙГАНЧЫ ИПИ АШЫЙСЫ ИДЕ

Без, әни белән мин, сеңлем Сабира, энем Габдулла калдык. Әнинең дә хәле бер дә яхшы түгел иде. «Әни, без кайчан үләбез?» – дип сорыйм әнидән. Ул исә: «Кызым, үлүен үләрбез, тик бер туйганчы ипи ашыйсы иде», – ди. Әти үлеменә бер ай булдымы икән, әнигә ипи ашатырга теләп, иртәнге 4тән чиратка басарга кибеткә киттем. Ипи алып кайттым. Әни мин киткәндә йоклап калган иде. Кайтсам, үлгән – ипине ашата алмадым. Ул төнне энем, сеңелем белән әнине кочаклап йокладык. Икенче көнне Ачасырдан килгән Хәририә апа белән Акъегеттән Газизә апа, әнине юып, кәфенләп, балконга чыгарып куйдылар. Бу – 16 февраль иде. Әни балконда озак ятты, җыеп йөрүчеләрнең тәки безнең әнигә чираты җитмәде. Болай яткырырга теләмичә: «Әйдә, әнине зиратка үзебез илтәбез», – дидем. Сеңлем кечкенә. Ул: «Ничек итеп?» – диюдән узмады. «Хәзер чана табып алып кайтам», – дип чыгып киттем. Табып кайттым кайтуын, ләкин чанага сала гына алмыйбыз. Үлгән кеше бик авыр була икән. Шуннан, күрше апага бер стакан ярма биреп, әнине чанага салырга ярдәм итүен үтендек. Чанага салдык та зиратка тартып киттек әниебезне. Чанадан төшерү тагын бер авыр булды. Җиргә одеал җәеп, әнинең гәүдәсен кардан күпмедер тартып бардык та зиратта калдырып киттек. Иртәгесе көнне тагын әниебезне карарга бардык. Ләкин ул юк иде инде. Белмим, күмгәннәрдерме... Әле дә белмим... Әни-әтинең гәүдәләре кайларда ятадыр, бүгенгә кадәр берәү дә белми. Укыган догаларым гына барып җитеп тапсыннар иде инде үзләрен...

## РӘНҖЕМӘ, ЭНЕМ...

Инде без өчәү калдык. Сеңлем, энем һәм мин... Туган якларга кайту юлларын эзли башладык. Көн саен шәһәрдән чыгарга «пропуск» сорап барабыз. «Рөхсәт юк» дигән сүзне бик күп тапкырлар ишеттек. Бервакыт, март айлары иде бугай, Ленинград блокададан чыкты. Безгә дә шәһәрдән чыгарга рөхсәт бирделәр. Без алты кыз идек. Ладога аркылы чыгу өчен машиналарга төялдек. Күп иде машиналар, берсе белән икенчесе арасында ераклык шактый. Безнең алдан баручы машина, шыгрым төялгән кешеләре белән, күз алдыбызда боз астына чумды да югалды. Әй, кызганыч та булды соң шул вакытта, әй, еладык та инде. Бернәрсә дә эшли алмадык, машина туктап тормады, туктаса, үзе дә чума бит. Чыгып җиткәнче беребез дә сөйләшмәдек. Аннан чыккач, шөкер, яхшы поездга эләктек. Без берничә көн ашамаган идек, ашханәгә барырга талон бирделәр. Шактый гына ризык тоттырдылар. Ипи, йомырка, шикәр... Ашап булмый – эчәгеләр кысылган. Ашарга өләшүчеләр безне: «Аз-азлап кына, ешрак ашагыз», – дип кисәтте. Шулай итеп, шәһәр саен туктап, 22 көнләп бардык та бардык без. Энем Габдулла авырып китте. Казанга кайта торган поездга утырасы килеп, һәрбер станциядә төшәбез дә, тагын шул поездыбызга куып кертәләр. Бер төшүебездә Габдуллага поездга менү бик кыенлашты. Хәле булмау сәбәпле, менә алмый, минем дә аны күтәрергә хәлем җитми. Безнең газапланганны күреп, хатын-кызлар: «Бу хәлегездә ник төшәсез? Утырыгыз җылы вагонда, үлсәгез дә, җылы вагонда үләрсез, башка төшмәгез», – дип, өчебезне дә күтәреп вагонга менгезеп утырттылар. Ярар, башка төшмик, үлсәк, җылы вагонда үләрбез, дип, төшмичә, поездда утыра бирдек.

Габдулланың авыруы көчәйгәннән-көчәйде. Озак та үтмәде, бичара, үлеп тә китте. Энем Габдуллага сигез яшь иде ул вакытта. Нинди шәһәр янында булганбыздыр, белмим, носилка белән алып чыгып киттеләр. Без икәү елап калдык. «Рәнҗемә, энем, рәнҗи генә күрмә», – дип еладык та еладык. Белмим, кайларга куйганнардыр...

## НЕМЕЦ АРТЫБЫЗДАН КАЛМАДЫ

Ишле гаиләнең тагын бер кешесен югалттык, сеңелем белән икәү генә калдык. Ярыйсы гына җылы вагоннарда Краснодар өлкәсенә барып җиттек. Ленинград блокадасыннан котылган кешеләрне алырга дип, урыслар үгезләр җигеп килгәннәр. Без вагонда унлап татар кызы идек. Бер колхозга алып килделәр – Усть-Лабинский районының Хатукай авыл советы иде. Авыл халкы безнең үгезләрдән төшкәнне карарга чыккан. Ник алып килгәннәр инде, мәетләр бит, барыбер үләчәкләр болар, дип каршы алдылар безне. Күңелләргә тагын да кыен булып китте. Безгә ике атна ял бирделәр. Ашау яхшы иде. Авызга ризык капкан саен, эх, боларны әти-әнигә, энебезгә ашатасы иде, дип уйлый идек. Ләкин булмады шул, булмады...

Безнең сөякләргә ит куна башлады. Тора-бара эшкә дә йөрерлек булдык. Дүрт кыз көнбагыш урдык, кукуруз сындырдык, алардан май әзерләүләрен ишетеп белә идек. Эшләгән өчен бодай бирәләр иде. Тук тамак белән тагын сигез ай вакыт үтеп китте.

1944 нең җәендә немецлар монда да килеп җиттеләр. Кайларга гына барсак та, немец артыбыздан калмады. Аларның бик усалланганнарын хәтерләмим. Алай да бервакыт, өч яшь солдат кызның борын, колакларын кисеп, бот итләренә кадәр ярып, урманда бик мәсхәрәләп үтергәннәр иде. Кызларның гәүдәләрен бүлмәдәге өстәлгә кертеп салдылар, мин дә кереп карадым. Хәзер дә ул гәүдәләр күз алдымда тора. Яшел төстәге киемнәре кызыл комач канга баткан иде...

Немецларның штабы без торган өйдән ерак түгел иде. Мин сеңелем белән гел татарча сөйләштем. Беркөнне шулай икәү, истәлекләргә чумып, нәрсәдер сөйләшеп утыра идек, немец киеме кигән бер хәрби урысчалатып, кайдан булуыбыз белән кызыксынды. Казаннан дигәч, безнең белән татарча сөйләшә башлады. Ул бездән кухняда булышуыбызны сорады. Аларга кишер кырып, бәрәңге әрчеп йөрдек. Яныбызга килеп, безнең белән рәхәтләнеп татарча сөйләшеп китә иде. Рус кызлары, немец телен кайдан беләсез, дип, бик аптырадылар. Мәктәптә өйрәнгәннәрдән дип алдашырга туры килде. Бу ярдәмебез бушка булмады. Ул абый, җаен табып, безне иттән дә, аш шулпасыннан да өзмәде...

...Бервакыт бик тирән кое янына бик күпләп немец солдатлары җыелганнар. Чиләге коега төшеп киткән икән. Хәзер нишләргә? Бер егет төшеп карады – булдыра алмады, инде мине күреп алдылар, син бәләкәй, дип, миңа төшәргә куштылар. Киреләнмәдем. Тактага утырттылар да, төрле яклап бәйләп, озын бау белән коега төшереп җибәрделәр. Озак төштем, берзаман аякларым суга тиде. Бауны селкетеп, сигнал бирдем. Суда чиләкне эзләү өчен тимер җайланма төшерделәр. Ике чиләк эзләп таптым, үзем коеда килеш, башта чиләкләрне менгезеп җибәрдем, аннан үземне тартып алдылар. Үзләренчә нәрсәдер сөйләнеп, шатланып, мине берсеннән икенчесенә йөртеп, аякларымны җиргә дә тидертми сикерттеләр, шулай рәхмәт әйтүләре булды бугай. Ике тапкыр төшәргә туры килде миңа ул коега. 90 метр тирәнлектә икәнен соңыннан гына белдем.

Бу авылда немецлар 8-9 ай чамасы тордылар. Туган якларга, авылга кайтулар булмас, ахры, дип йөргәндә шатлык елмайды. Шулай иртә белән йоклап ятканда «Торыгыз, торыгыз, безнең совет солдатлары авылда» дигән тавышка уянып киттек. Әй, сөенгәнебезне

белсәгез. Бөтен кеше урамда иде инде. Солдатларны каршы алдык. Араларында хатын-кызлар да күп иде. Яшькелт төстәге киемнәре хәзер дә күз алдымда тора. Аякларында итек дигәннең «и» хәрефе дә калмаган, табаннары купкан... Хәрбиләр авылда бераз гына хәл алдылар. Безнең янга килеп, хәлләребезне сораштылар. Шунда бер солдат, минем татар телендә сөйләшкәнне ишетеп, моннан 30 чакрымда татар авылы бар, сез шунда барырга тырышыгыз, диде. Озак тормадылар, стройга тезелеп, китеп бардылар..

## ӘТИДӘН КАЛГАН ПӘЛТӘ

Алты татар кызы татар авылны эзләп чыгып киттек. Барып таптык. Идарәдә Мәмәт исемле бер абый эшли иде. Ул безне төрле гаиләләргә урнаштырды. Сеңлем бер остабикә өенә эләкте, аның өчен күңелем тыныч булды.
Ә үзем ирле-хатынлы бер гаиләдә яши башладым. Ләкин алар бик усал булып чыктылар. Ул елларда бүреләр күп иде. Авыл мичләре утын белән ягыла. Мине берүземне генә урманнан утын кисеп алып кайтырга җибәрәләр. Үзем куркам, ләкин иртә таңнан гаиләне уятмый гына, алар торганчы утын кисеп кайтып, мичкә ягып җибәрәм. Беркөнне урманнан кайтуыма каршымда Мәмәт абый басып тора. Бик ачуланып, өйгә кереп китте. Хуҗалар йоклап ята иде, аларны бик каты орышып, хәтта идарәгә чакыртып, штрафлар да салдырганын хәтерлим. Шуннан соң мине улы белән генә яшәүче бер апага керттеләр. Озак та үтмәде, улы Якубны армиягә алдылар. Без хуҗа апа белән матур гына икәү яши башладык. Беркөнне безгә кунакка апаның туганы килде. «Бу кызың бик уңган, Якуб армиядән кайтсын да, өйләндерерсез», – димәсенме! Мине ток суккандай булды, авылга кайтырга кирәк дигән уй тагын калкып чыкты. 1945 елның март айларында сеңлемне алдым да, безгә Кукмара, Чистай кызлары да иярде, туган якка кайтырга чыктык. Ник чыктым көненә калдым. Аякта ботинка, салкыннан аяклар өшеде, өстә этидән калган пальто, җитмәсә, тәнне бетләр ашый. Поездларга билетлар юк, подножкада кайтабыз. Сеңлем Сабира булды, аңа рәхмәтлемен, ул булмаса, үлеп тә калган булыр идем. Башка барыр хәлем юк, булмый, дип, мин тимер юлга ятам. Сеңелем, әйдә инде, апам, тор, дия-дия, тәки кайтып җиттек. Унбиш көнләп кайтканбыздыр. Җиде кешедән бары икебез генә туган авылыбызга әйләнеп кайттык. Авылыма рәхмәт, рәхәт эзләп чыгып киткән, җиде ел сукбайлыкта йөргән балаларын үзенә сыендырды, матур каршы алды.

## МАТУР ЯШӘДЕК, СИГЕЗ БАЛА ТАПТЫМ

Кияүгә чыгып, Финляндиягә бармый калган олы апабыз авылда гаиләсе белән яши иде. Без сеңелем белән шуларга кайтып кердек. Апа безне мунча кертте, чистартты. Авылда туган йортыбыз буш иде, шунда күчтек. Ләкин ул бик зур булу сәбәпле, аны сатып, кечкенәрәк өй алдык. Сеңлем белән бергә яшәдек. Мин тавык фермасына эшкә урнаштым. Бер елга торфка барып, аннан киенеп тә кайттым. Паспорт алу теләге белән авыл советына бардым. Ул вакытта паспорт бирми тилмертәләр иде. Анда, башта армиядә, аннан сугышта сигез ел йөреп, яңа гына кайткан Ярхәм исемле егет эшли иде. Миңа күзе төшкән булган, ахрысы, паспорт бирмәде. Шулай итеп, бераз сөйләшеп йөргәннән соң, 1948 елның март аенда Ярхәмгә кияүгә чыктым. Матур яшәдек, сигез бала таптым. Бүгенге көндә өчесе исән-сау. – ике кыз, бер малай. Төрлесе төрле якларга таралышып беттеләр – Кырым-Ялтада, Ленинградта, улым Яшел Үзәндә яши.

Гомерем буе авылда кырчылык бригадасында эшләдем. Чөгендер эшкәрттек, бәрәңге алдык, урак урдык. Ирем 89 яшендә үлеп китте. Бик ипле кеше иде, башта авыл советы, аннан – партком секретаре булды, соңыннан мәктәптә эшләде. Бик еш кына газетага мәкаләләр яза иде.
82 яшемә кадәр хуҗалыгыбызда сыер асрадык. Бәрәңгенең кабыгын да әрәм итмәдем. Хәзер инде кыш көне улым белән килен янәшәсендә Яшел Үзәндә яшим.

**КЕЧЕ АПА**

Алар икесе дә шушы көнгә кадәр туган авылларында гомер иткәннәр. Чит җирләрдә шундый авырлыклар күреп, туган авылларыннан китмәскә дип кайталар бит алар. Апасы сөйләгәнне тыңлап утырган Сабира апа да хатирәләрен барлады.
– Мин 27 яшемдә кияүгә чыктым. Ирем Габбас белән бер кыз, ике ул тәрбияләп үстердек (Сәрия, Илдус, Җәүдәт). Кайнатам Зариф бик хөрмәтле, мәрхәмәтле кеше иде. Ул көтүче булып эшләде. Гомере буе хуҗалык көтүен көтте. Әле дә булса исеме авылдашлар теленнән төшми. Үзем гомер буе, пенсия ялына чыкканчы, фермада сыер савучы булдым. Эшемне яратып башкардым, алдынгы савымчылардан булдым. Өйгә дә кайтмый сыерларга махсус азыклар пешереп ашата идем. Исемемне дә Кечкенә Сабира дияләр иде. Кечкенә булдым: ач булгач, үсеп тә булмый шул. Аякларым пеште минем, шулай бит, Кече апа, – ул, сөйлим микән дип рөхсәт сорагандай, апасына карап алды. Бу якларга гына хас булганча, Сабира апа Вафирә туганына яратып «Кече апа» дип эндәшә.
– Шулай, сеңлем, шулай.
– Тукта, монысын үзем сөйлим әле, – дип, Сабира апа тагын сөйләп китте. – Ленинградта атулар тынып торган вакытларда җылы шулпа өләшәләр иде. Мин кечкенә, аякларымны сузып, түземлек белән эти-әнинең шулпа алып килгәнен көтеп утырам. Шулвакыт берәү минем аякларыма абынып егылды. Кулындагы шулпасы минем аякка түгелде. Ике аягым да пеште, бик авыртты. Төзәлеп тә бетмәгән аякларым белән бомбага тоту вакытында окопка сикерәм. Ничекләр түзелгән, исләремә төшсә, хәзер дә тәннәрем чемердәп китә. Ике айлап төзәлде бугай ул. Ә аннан кайткач, фермада, башта – чабата, аннан резин итекләр аяктан төшмәде. Аякларым бик авырта, йөрүе дә көннән-көн кыенлаша. Табибларга бер үпкәм бар – миңа шушы аягым белән икенче группа инвалидлык бирделәр. Шулвакыт ирем Габбас авырып китте, үзе авыруым белән хастаханәгә яту, табибларга күренү һаман сузылды. Габбас терелеп, аякка басып, күзләрем ачылып киткәч, район табибларына барып карадым. Вакытында рәсмиләштерергә кирәк иде, диделәр. Менә, Аллага шөкер, шул аякларым белән, чатанлап булса да, йөреп маташам. Йөрергә язсын, инде күпме калгандыр... – Сөйләнә-сөйләнә бик кыенлык белән атлап чыккан Сабира апа: – Күрде инде башлар, ачлык-ялангачы да булды, – диде. – Бер чага (агач гөмбәсе) белән дә тамак туйдырган чаклар аз булмады. Ә хәзер камырны өйдә салам икән, пирогның соңгы кисәген, калган почмагына кадәр җебетепләр ашап бетерәм. Аны терлеккә ашатырга да кулым бармый. Хәзер, мең шөкер, табын тәмле, татлы ризыклардан сыгылып тора. Мең шөкер, мең шөкер, боларны күрермен дип, төшкә дә кермәгән иде. Ә бу яшькә җитәрмен, 95 яшемне тутырырмын диеп уйлау түгел... Эх, эти-әни генә бик яшьли китеп бардылар, аларга күрсәтәсе иде бүгенге муллыкны. Ашатасы иде, юк шул, юк, ашатып булмады... Кече апа, хәтерлисеңме, чәйне Финляндиядә дә, Краснодарда да самовардан эчтек. Аны бит эти-әни Акъегеттән алып барганнар иде. Самовар Краснодарда калды. Әти-әни Ленинградта ятып

калдылар. Кече апа, хәтерлисеңме, бервакыт әти кайтты да сөйли. Мин бала инде, мине исәпкә алмый сөйләшәләр: «И, Гыйният, үзбушаткыч машина белән алып килделәр бер олау мәетләр, алдан әзерләнгән чокырга ничек төште шулай атып, күмеп киттеләр. Безгә дә килә бит бу көн, ләкин кайчан, эх, бераз яшисе иде, шушы балалар хакына», – дип. Юк, озаклап яшәргә насыйп булмады бәгырьләргә. Ачлы-туклы Ленинград блокадасы бетте, Ладога күленнән чыктык, ә Краснодарда тәмле ашап яшәдек, Кече апа, әйеме. Кукуруз боткасы пешерә идек. Кавын-карбыз үстерә идек. Бакчада алыча агачы төбендә йоклаган чаклар да шактый булды.

– Ә хәтерлисеңме? – диеп, Вафирә апа бүлде аны. – Бер тәмле ризык булып күңелемдә калган, сарымсакны махсус таш белән изәләр иде, май белән кыздырып ашый идек, тәмле иде инде.

– Тәмле иде, Кече апа. Ә берзаман, син хәтерлисең микән, Кече апа, сез мине, кечкенә дип инде, алма бакчасына җибәрдегез. Анда немецлар бал корты оясыннан бал белән тулы кәрәзләр алалар иде. Озын-озын буйлы немец солдатлары кәрәзне алырга чиратка басканнар, мин дә үземнең кечкенә генә, чатан аякларым белән берсенең артына килеп бастым, үзем куркам. Миңа да чират җитте, ояның эченә бәләкәй генә кулларым белән кереп китеп, бер кәрәзен тартып чыгардым да кайтып киттем. Бал кортлары чакканны да хәтерләмим, ә тәмләп ашаган хәтердә.

– Хәтерлим, хәтерләмимме соң, – дип, Вафирә апа кушылды. Бер-ике тапкыр шулай бал алып кайтып сыйладың син безне. Ә бервакытны, хәтерлисең микән, Краснодарда колхоз йортында торган чакларда Норлат кызы Резедә белән икегезгә немецлар конфет биреп китә торган булдылар. Дуслашып та киттек кебек. Бер төнне ишекне шакыйлар, куркып калдык, ачу юк инде, тыныч кына качып ятабыз. Ишекне ватып керде бер немец солдаты. Үзенчә нәрсәдер аңлата, мич янына килеп, нәрсәләрдер сөйли. Безне юрган астыннан җилтерәтеп урамга чыгарып җибәрде. Урамга чыккач кына аңладык: мичкә күп ягып җибәргәнбез икән, морҗа яныннан ут капкан булып чыкты. Солдатлар сүндерделәр, алар безне шулай үлемнән дә алып калдылар әле.

Финляндиядә вакытта өченче класста безне, алты баланы, бергә Татарстаннан килгән Гариф абый укытты. Чукмар башлы каләм белән яза идек, кәгазе сары, үзе зур. Дәфтәр зурлыгында итеп кисеп, юлларын үзебез сызып әзерли идек. Тәнәфескә дә чыкмый утырган чаклар бик еш булды. Чөнки безнең белән Норлаттан килгән игезәк егетләр Габдрахман белән Габдразак сөйли башласалар, һәрберебез, бөтен дөньяларыбызны, хәтта тәнәфесне дә онытып, аларны тыңлый идек. Матур, безнең өчен кызыклы темаларны белеп сөйлиләр иде. Норлатыбыз киләчәктә шәһәр булмаса да, бик зур авыл булачак, дип, шул елларда ук туган авылларына карата үз фикерләрен җиткерүләре хәтеремдә калган. Әй... ул егетләр исән-сау булсалармы, нинди галимнәр булырлар иде. Сугыш харап итте.

Читтә каласы килми, кызларның. Туган якларына кайту теләге көчле була. Краснодардан Мәскәүгә поездда өч тәүлек баралар алар. Поезд туктаган вакытта су эзләп төшкән кызларны милиция тотып алып китә. Милиция бүлмәсендә калай бакларда су күреп, бер кешегә игътибар итми, су эчәләр алар. Яхшы гына шелтә дә эләгә үзләренә, шулай да эчәсе килү теләген басалар. Сорау алулар: кайларга барасыз, кайлардан кайтасыз, ничек, нәрсә?.. Бары тик Ленинград блокадасыннан чыкканлык турындагы кәгазьне күрсәткәч кенә җибәрәләр. Шулай итеп, кызлар поездан калалар. Аннан – Казан, Свияжск, бу шәһәрләрдә дә шундый ук сорау алулар кабатлана. Шуннан Ормар тукталышына җитәләр. Туган авылларына турыдан сигез чакрым. Шулай мең газаплар белән олы апалары гаиләсенә кайтып керәләр.

Алар шулай берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә бик күп истәлек-хатирәләре белән уртаклаштылар. Әле күпмесе күңелләре түрендә саклана...

**ҮТКӘННӘРНЕ ҮПКӘЛӘТМИ**

Быел Сабира апа Ганиева үзенең 95 яшьлеген билгеләп үтте (9 апрель көнне ул бакыйлыкка күчте). Ә Вафирә апа Вәлитовага июнь аенда 100 яшь тулды. Ходай аларга гомерне, хәтерне зурдан биргән. Бәлки алар әти-әниләре, чит җирдә үлеп калган өч туганнары өчен дә яшиләрдер. «Әтигә бары тик 55 яшь иде, ә әнием 45 яшендә мәрхүм булды. Энем Габдуллага 8 яшь, ике туганымның берсе 2 ел, икенчесе 5 ел гына яшәп калдылар якты дөньяларда», – дип кабатлый Вафирә апа. Адәм баласының үткәннәрне искә төшереп яшәве, аның бүгенге дөньяга мөнәсәбәтен, карашын, кадерен арттыра, мин моңа янәдән инандым. Ике шәхес: Вафирә, Сабира. Алар кичергән кайгы һәм шатлыклар белән тулы гомер мизгелләре бик күпләребезгә сабак булырлык. Бер язучыбыз әйткәндәй «Үткәннәрне үпкәләтми, киләчәкне үртәми» тыныч кына яшәргә язсын аларга.




Вафира апа Сабира апа белән

**«...ӘНИНЕ ЮЫП, КӘФЕНЛӘП, БАЛКОНГА ЧЫГАРЫП КУЙДЫЛАР»**

«Яшел Үзән» газетасында басылган, югарыдагы «Гыйбрәтле язмыш иясе Акъегет кызы» («Яшел Үзән» № 26, 27, 2020) язмасының икенче өлешен бик кызыксыну белән көтеп ала Яшел Үзән шәһәрендә яшәүче Шәүкәт Гыйззәтуллин. Язмада «Икенче көнне Ачасырдан килгән Хәрирә апа белән Акъегеттән Газизә апа, әнине юып, кәфенләп, балконга чыгарып куйдылар» дигән сүзләрне укыгач, аның йөрәге туктагандай булып, башкача тибә башлый... Алар гаиләләре белән мәкаләне кат-кат кычкырып укыйлар. «Ачасырдан килгән Хәрирә апа» – шушы сүзләр тетрәндерә аны. Ә ул, алты яшьлек сабый, 1941 елда уналты яшьлек Вафирә кичергән газапларны күтәрә. Шәүкәт – Хәрирә апаның улы. Балачак хатирәләрен яңарта ул, ләкин бик азы, бик азы гына күңел төпкелләрендә сакланган шул... Әнисе Хәрирә сиксән яшендә мәрхүм була, Шәүкәт ага үзе дә инде туксан яшен тутырып килә. Язма хуҗасын, аның төп герое Вафирәне табу теләге Шәүкәтне «Яшел Үзән» газетасы редакциясенә китерә.



Сулдан уңга Вафира, Шәүкәт, Сабира

**«АКЪЕГЕТ» БЕЗНЕҢ ӨЙДӘ ЯШИ...**

Шәүкәт абый, телефон номеры кулына эләгүгә, шалтырата, башта Сабира апа белән, аннан Вафирә апа белән сөйләшә. Ләкин, күрешеп, күзгә-күз карап сөйләшүне берничек тә телефон аша гәпләшүгә алыштырып булмый. Вафирә апа Чаллыдан туган авылы Акъегеткә

кайткач очрашырга килешәләр. Мин үзем, бик-бик теләсәм дә, бу очрашуның шаһиты була алмадым. Ләкин бу – күзләрдән яшьләр китерә торган сокландыгыч очрашу булуына иманым камил.
– Газетадагы язманы укыгач, йокым качты. Күреп сөйләшәсе килү теләгемне әйтеп кенә аңлатып булмый. Кош булсам, минутында очкан булыр идем, – дип сөйли Шәүкәт абый. Килешенгән көнне кунакларны Акъегет авылында түземсезлек белән көтәләр. Машинада кияү, кызлары, хатыны янәшәсендә Шәүкәт абый. Ул машинадан төшкәндә кунакларны каршыларга чыккан Вафирә апа: «Кара әле, Зиннәт абый бит бу», – дип куя. Әйе, Вафирә апа сүзе буенча, Шәүкәт әтисе Зиннәткә ошаган икән. Финляндиягә киткәндә, 1939 елда, аңа дүрт яшь була. Сугышның беренче көнендә үк әтиләрен сугышка алалар. Ә Шәүкәт әтисен хәтерләми. Вафирә апа берсе артыннан икенче соравын яудыра:
– Ә туганнарыңны хәтерлисеңме?
Шәүкәт абый җилкәләрен генә селкетеп, башын гына чайкап «Юк хәтерләмим» дигәч үк, Вафирә апа үзе үк җавап та бирә:
– Биш туганың бар иде синең. Хәрирә апа Зиннәт абыйның икенче хатыны иде. Хәлбәрия белән Равил – беренче хатын балалары, аннан – Наилә, Илдус.
Вафирә апа аларның һәрберсен белә, ябык кына, озын буйлы Шәүкәтне дә бик яхшы хәтерли. Ленинградта блокада вакытында бер бүлмәдә яшәргә, җан асрарга туры килә аларга. Ләкин барысының да гомерләре бик кыска булып чыга. Блокададан әнисе белән Шәүкәт кенә исән-сау чыгалар. Аннан – Краснодар. Әмма, ни сәбәпледер, Шәүкәт абый боларның берсен дә хәтерләми...
1943 елда Хәрирә апа улы белән туган ягына кайтып төшә. Шәүкәт сугыш беткән елны, ун яшендә, беренче класска бара. 1951 елда Ачасыр мәктәбенең җиде классын тәмамлаган егетне армия сафларына алалар. Өч ел ярым гомере хезмәттә үтә. Аннан Волжск шәһәрендә шофер булып эши.
– Әнием белән сөйләшеп утырырга да вакытым булмады минем. Ул колхоз эшеннән кайтып кермәде. Мин аңа булышып йөрдем бугай. Шулай менә гомер үтелгән. Ленинград блокадасыннан исән калган бала син, дип әйтә иде әнием.
Ул Яшел Үзәндә үзе белән бергә Ленинградта булган Норлат кызы Резедәне очрата. Резедәнең дә ул елларның шаһиты булганлыгы хакында бер документы да булмый. Кирәкми, ди Резедә, инде күпме яшисе калгандыр дип, бу темага сөйләшәсе дә килми. Озак та тормый Резедә гүр иясе була. Ә Шәүкәтнең хатыны Илгизә ханым кайларга гына мөрәҗәгать итми, кемнәргә генә язмый. Хәрирә турында мәгълүматлар табыла, ә уллары хакында – юк. Эзләүнең очына чыгып җитә алмыйлар, ярты юлда тукталалар. Әй, кирәкми инде ул миңа, дип әйтергә ашыга Шәүкәт абый да. Әйе, кирәкми, ни бирә ул? Ни бирә өчен түгел, дөреслекне күрсәтү өчен кирәк бит ул. Ә бүгенге көндә аның Ленинград блокадасы документларын кулларында тотып торучы ике шаһиты бар. Бу исемне Шәүкәт абый да хаклы рәвештә йөртә ала. Җитәкчеләр игътибар итсеннәр иде, кайтарсыннар иде тиешле исемне.
Шәүкәт абый Акъегет кызларына рәхмәт сүзләрен яудыра: «Тфү-тфү, хәтерләре яхшы, гомерләрен дә бирсен Ходаем!»
– Безнең өйдә «Акъегет» яши хәзер, – дип көлемсерәп куйды ул.
– Ничек инде?
– Ничек, дип, – сүзгә хатыны Илгизә апа кушыла. – Акъегет авылында Вафирә апалар хуҗалыгы иң соңгы йорт. Килгән кунаклар караңгы төшкәндә генә юлга кузгалалар. Кызлары шунда машина янәшәсендә бер мәче баласын күреп ала. Ләкин кулына алырга,

сөяргә кыюлыгы җитми. Машина акрын гына кузгалып киткәч тә мәче, бәләкәй аякларына бер басып, бер егылып, мәтәләнә-мәтәләнә, машина артыннан ут яктысына йөгерә. Машинаның арткы тәрәзәсеннән бу хәлләрне күзәткән кызга мәче баласы бик тә кызганыч булып китә. Туктагыз, алыйк әле теге мәчене, диеп, машинаны туктата. Алалар, бары тик өйгә алып кайткач кына мәченең авыру булуы ачыклана. Салган сөтне дә тәмләп эчә алмый, азаплана бәгырь. Әйтерсең, 900 көн торып, блокададан чыккан: ач, тавыру... Мәчене мал табибына алып барып дәвалыйлар. «Акъегет» диеп исем кушалар. «Менә хәзер «Акьегет» безнең өйдә», – диеп елмаялар алар.
Шәүкәт абыйга 90 яшьне биреп тә булмый. Аның буй-сыны егетләрнеке кебек, күңеле көр, тавышы яңгыравык. Мин, китәргә җыенгач, яшь вакытында җырчы булгансыздыр әле, дип әйтеп куйдым. «Әй, булды инде, ул вакытта барыбыз да җырлый идек», – диде. Мин аннан, әйдәгез, шул елларда яратып башкарган бер җырны җырлагыз әле, диеп сорадым. Ул озакка сузмый «Җидегән чишмә»не сузып та җибәрде:

*...Сез каласыз инде, без китәбез,*
*Без китәбез ерак илләргә.*

Шәүкәт абый матур җырлады. Яшь вакытларында сәхнә түреннән төшмәгәндер, җыр-моңнары белән халык күңелен яулагандыр ул.
Ул җырлаган көйне эчтән генә көйләп, сөйләшкән сүзләрнең очына чыгып, бер җепкә тезәргә тырышып, Шәүкәт Зиннәт улы Гыйззәтуллиннар гаиләсе белән саубуллаштым.

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА,**
китапханәче,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Автор фотолары.

(«Мәйдан» журналы, № 6, 2025 ел)

*(«Мәйдан» журналы, № 6, 2025 ел)*